УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«28» июнь, 2024 ел Казан ш. № 21

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2018 елның 1 мартындагы 14 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2018 елның 1 мартындагы 14 номерлы боерыгына (2023 елның 7 сентябрендәге 43 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Идарә) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларның үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»;

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Килештерү гариза алынганнан соң 10 көн эчендә башкарыла.»;

3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

3.4.2 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән белдерү» сүзләрен «3.1 пунктның «б» пунктчасындагы бишенче абзацында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә белдерүләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

3.4.3 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә белдерүләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин катнашында карала. Дәүләт хезмәткәре яисә гражданин Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчаларына ярашлы рәвештә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә күрсәтә.»;

3.8.1 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчаларында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында күрсәтелмәсә;

түбәндәге эчтәлектәге 3.18.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын яңа редакциядә (кушымтада) бәян итәргә.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы И.Ф. Бәдриев

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты ГХАТ
идарәсенең 2018 елның 1
мартындагы 14 номерлы боерыгы
белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты ГХАТ
идарәсенең 2024 елның 28
июнендәге 21 номерлы боерыгы
редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе

**СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| Бәдриев И.Ф. | – | Идарә җитәкчесе урынбасары, Комиссия рәисе; |
| Липовая С.И. | – | Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге җитәкчесе, Комиссия рәисе урынбасары; |
| Александрова О.А. | – | Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, Комиссия секретаре. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Т.Р.Хәлимдаров | – | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең коррупциягә каршы мониторинг бүлегенең баш киңәшчесе (килешү буенча); |
| Т.И.Леонтьева | – | «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» АКО генераль директоры, Идарә каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча); |
| В.Б.Паймухин | – | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты каршындагы Экспертлар советы рәисе, «Россия юристлары берләшмәсе» әгъзасы 9килешү буенча); |
| Миңнегалиева Э.И. | – | Идарәнең мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлеге җитәкчесе; |
| Плисцова Е.И. | – | Идарәнең ресурслар белән тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары секторы мөдире. |